| МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.12.2015 Казан ш. № 02-142

Россия Федерациясе бюджет классификациясен Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте бюджетына кагылышлы өлешендә куллану тәртибен урнаштыру, детальләштерү һәм билгеләү турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2014 елның 31 декабрендәге 02-135 номерлы боерыгы белән расланган күрсәтмәләргә үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

Россия Федерациясе бюджет классификациясен Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте бюджетына кагылышлы өлешендә куллану тәртибен урнаштыру, детальләштерү һәм билгеләү турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2014 елның 31 декабрендәге 02-135 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2015 елның 31 мартындагы 02-35, 2015 елның 2 июлендәге 02-62 номерлы боерыклары редакциясендә) расланган күрсәтмәләргә кертелә торган кушымта буларак бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс
министрлыгының 2015
елның
«29»декабрендәге
№ 02-142
боерыгы белән расланды

Россия Федерациясе бюджет классификациясен Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте бюджетына кагылышлы өлешендә куллану тәртибен урнаштыру, детальләштерү һәм билгеләү турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2014 елның 31 декабрендәге 02-135 номерлы боерыгы белән расланган күрсәтмәләргә үзгәрешләр

1. «Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды чыгымнары исемлеге һәм аларны тиешле максатчан статьяларга кертү кагыйдәләре» 1.1. пунктында:

а) «2020 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасы» 1.1.1. пунктчасында:

«Авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен булдыру. Башлангыч медицина-санитария ярдәмен үстерү» ярдәмче программасы» 01 1 0000» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле чыгымнарны өстәргә:

«- 5482 Гражданнарны дарулар белән тәэмин итүне яхшырту максатларында

Әлеге юнәлеш буенча гражданнарны дарулар белән тәэмин итүне яхшырту максатларындагы чараларны гамәлгә ашыруга бәйле федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«Махсуслаштырылган, югары технологияләне дә кертеп, медицина ярдәмен, ашыгыч, шул исәптән махсуслаштырылган ашыгыч медицина ярдәмен күрсәтүне, медицина эвакуациясен камилләштерү» ярдәмче программасы 01 2 0000» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 5422 Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары буйсынуындагы медицина оешмалары тарафыннан 2014 – 2015 елларда Украина гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга медицина ярдәме күрсәтүгә һәм эпидемия күрсәткечләре буенча профилактик прививкалар календарена кертелгән профилактик прививкалар ясауга бәйле чыгымнарны компенсацияләү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары буйсынуындагы медицина оешмалары тарафыннан 2014 – 2015 елларда Украина гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга медицина ярдәме күрсәтүгә һәм эпидемия күрсәткечләре буенча профилактик прививкалар календарена кертелгән профилактик прививкалар ясауга бәйле чыгымнарны компенсацияләүгә юнәлдерелгән федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

б) 1.1.2. «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы» пунктчасында:

«02 2 0000 «2014 – 2020 елларга гомуми белем бирүне, инклюзивны да кертеп, үстерү һәм әлеге өлкә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 5026 2011 – 2015 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасы чараларын финанс белән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча 2011 – 2015 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасы чараларын финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

- 5088 Иң яхшы укытучыларны бүләкләү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча иң яхшы укытучыларны бүләкләүѓә федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«02 4 0000 «2014 – 2020 елларга һөнәри белем һәм югары уку йортыннан соңгы белем бирүне үстерү һәм әлеге өлкә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 5026 2011 – 2015 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасы чараларын финанс белән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча 2011 – 2015 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасы чараларын финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

- 5066 Россия Федерациясе халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарәче кадрларны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән әзерләү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Россия Федерациясе халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарәче кадрларны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән әзерләүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«02 К 0000 «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 5027 Татарстан Республикасында уңайлы мохитне субсидияләр исәбеннән булдыру чаралары

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында Татарстан Республикасында уңайлы мохитне булдыру чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

в) 1.1.3. «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасы» пунктчасында:

«03 2 0000 2014 – 2020 елларга «Өлкән яштәге гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 5209 Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуга, эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтүгә һәм компьютер белеме бирүгә бәйле социаль программаларын субсидияләр исәбеннән финанслашу

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуга, эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтүгә һәм компьютер белеме бирүгә бәйле социаль программаларын субсидияләр исәбеннән финанслашуга Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«03 3 0000 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 5209 Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуга, эшләмәүче пенсионерларга

адреслы социаль ярдәм күрсәтүгә һәм компьютер белеме бирүгә бәйле социаль программаларын субсидияләр исәбеннән финанслашу

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуга, эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтүгә һәм компьютер белеме бирүгә бәйле социаль программаларын субсидияләр исәбеннән финанслашуга Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«03 6 0000 2014 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасы максатчан статьясында наименование направления расходов «-5027 «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасының 2014 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыру» чыгымнары юнәлеше исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 5027 Татарстан Республикасында уңайлы мохитне субсидияләр исәбеннән булдыру чаралары»;

г) 1.1.4. «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасы» пунктчасында:

«04 1 0000 «2014 – 2015 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлеше өстәргә:

«- 5020 Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән субсидияләр исәбеннән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«04 К 0000 «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 5021 «2011 – 2015 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Россия Федерациясе субъектларының торак төзелешен үстерү программаларын камилләштерү» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «2011 – 2015 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Россия Федерациясе субъектларының торак төзелешен үстерү программаларын камилләштерү» ярдәмче программасы

чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

д) 1.1.8. «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасы» пунктчасында:

«08 1 0000 «2014 – 2020 елларга музей эшен оештыру» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 5014 «Россия мәдәнияте (2012 – 2018 еллар)» федераль максатчан программасы чараларын гамәлгә ашыру»

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Россия мәдәнияте (2012 – 2018 еллар)» федераль максатчан программасы чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«08 3 0000 «2014 – 2020 елларга китапханә эшен үстерү» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 5014 «Россия мәдәнияте (2012 – 2018 еллар)» федераль максатчан программасы чараларын гамәлгә ашыру»

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Россия мәдәнияте (2012 – 2018 еллар)» федераль максатчан программасы чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«- 5146 Россия Федерациясенең гомумфайдалану китапханәләрен «Интернет» челтәренә тоташтыру һәм, мәгълүмат технологияләрен киңәйтү һәм цифрлаштыру бурычын исәпкә алып, китапханәләр эше системасын үстерү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Россия Федерациясенең гомумфайдалану китапханәләрен «Интернет» челтәренә тоташтыру һәм, мәгълүмат технологияләрен киңәйтүгә һәм цифрлаштыру бурычын исәпкә алып, китапханәләр эше системасын үстерүгә федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«08 В 0000 «2014 – 2020 елларга регионара һәм милләтара мәдәни хезмәттәшлекне үстерү» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 4405 Грантлар»;

«08 Ж 0000 «2014 – 2020 елларга тармакның дәүләт идарәсе системасын үстерү» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 5014 «Россия мәдәнияте (2012 – 2018 еллар)» федераль максатчан программасы чараларын гамәлгә ашыру»

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Россия мәдәнияте (2012 – 2018 еллар)» федераль максатчан программасы чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

е) 1.1.9. ««2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» дәүләт программасы» пунктчасында «09 4 0000 «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы су хуҗалыгы комплексын үстерү» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 5016 Татарстан Республикасы су хуҗалыгы комплексын субсидияләр исәбеннән үстерү гамәлләре

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасы су хуҗалыгы комплексын субсидияләр исәбеннән үстерү гамәлләренә федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

ж) 1.1.10. «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасы» пунктчасында:

«10 1 0000 «2020 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасы» максатчан статьясы исемендә «Татарстан Республикасында» сүзләрен төшереп калдырырга;

«10 К 0000 «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 5017 «2008 – 2015 елларга Россия Федерациясендә футболны үстерү» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыру»

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «2008 – 2015 елларга Россия Федерациясендә футболны үстерү» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

з) 1.1.11. «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасын икътисадый үстерү һәм аның инновацион икътисады» дәүләт программасы» пунктчасында:

«11 3 0000 «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 5085 Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм чаралары

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле яңа максатчан статья өстәргә:

«11 5 0000 «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасы»

Әлеге максатчан статьяда чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча ярдәмче программаны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 5389 Инновацион территориаль кластерларны үстерү буенча комплекслы инвестицион проектларны субсидияләр исәбеннән гамәлгә ашыру чаралары

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча инновацион территориаль кластерларны үстерү буенча комплекслы инвестицион проектларны субсидияләр исәбеннән гамәлгә ашыру чараларына федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

- 6389 Инновацион территориаль кластерларны үстерү буенча комплекслы инвестицион проектларны гамәлгә ашыру чаралары

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча инновацион территориаль кластерларны үстерү буенча комплекслы инвестицион проектларны гамәлгә ашыру чараларына Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

и) 1.1.13. «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасы» пунктчасында:

«13 4 0000 «2014 – 2022 елларга автомобиль, шәһәр электр транспортын, шул исәптән метроны үстерү» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 5480 Троллейбуслар һәм трамвай вагоннары сатып алу

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча троллейбуслар һәм трамвай вагоннары сатып алуга федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;.

- 6480 Троллейбусларны һәм трамвай вагоннарын Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән сатып алу

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча троллейбусларны һәм трамвай вагоннарын Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән сатып алуга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары чагылдырыла.»;

«13 6 0000 «2014 – 2022 елларга автомобиль юллары челтәрен камилләштерү, үстерү һәм саклап калу» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 0356 Чаллы шәһәренең сәнәгать зонасында гомуми файдаланудагы юллар инфраструктурасын Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән булдыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Чаллы шәһәренең сәнәгать зонасында гомуми файдаланудагы юллар инфраструктурасын Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән булдыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 0357 Чаллы шәһәренең сәнәгать зонасында гомуми файдаланудагы юллар инфраструктурасын «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциягә карамаган оешмасы акчалары исәбеннән булдыру»

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Чаллы шәһәренең сәнәгать зонасында гомуми файдаланудагы юллар инфраструктурасын «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциягә карамаган оешмасы акчалары исәбеннән булдыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла;

к) 1.1.14. «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы» пунктчасында:

«14 1 0000 ««Үсемлекчелекнең ярдәмче тармагын, үсемлекчелек продукциясен эшкәртүне һәм реализацияләүне үстерү» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 5450 Үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен эшкәртүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен эшкәртүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасы өлешен каплауга федераль бюджет акчалары исәбеннән булдыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«- 6035 «2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү» икътисадый әһәмиятле ведомство максатчан региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү» икътисадый әһәмиятле ведомство максатчан региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«- 6450 Үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен эшкәртүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен эшкәртүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«14 2 0000 «Терлекчелекнең ярдәмче тармагын, терлекчелек продукциясен эшкәртүне һәм сатуны арттыру» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 5442 Сөт юнәлешендәге терлекчелек комплекслары объектларын (сөтчелек фермаларын) төзүгә һәм модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча сөт юнәлешендәге терлекчелек комплекслары объектларын (сөтчелек фермаларын) төзүгә һәм модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнар өлешен каплауга федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

- 5443 Сөт терлекчелеген үстерүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча сөт терлекчелеген үстерүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасы өлешен каплауга федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

- 5444 Сөт терлекчелеге объектларын төзүгә һәм реконструкцияләүгә инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча сөт терлекчелеге объектларын төзүгә һәм реконструкцияләүгә инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процент ставкасы өлешен каплауга федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 5450 Үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен эшкәртүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен эшкәртүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасы өлешен каплауга федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«- 6443 Сөт терлекчелеген үстерүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча сөт терлекчелеген үстерүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 6444 Сөт терлекчелеге объектларын төзүгә һәм реконструкцияләүгә инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча сөт терлекчелеге объектларын төзүгә һәм реконструкцияләүгә инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 6450 Үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен эшкәртүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен эшкәртүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«14 3 0000 «Ит терлекчелеген үстерү» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 6051 «2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит терлекчелеген үстерү» ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит терлекчелеген үстерү» ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«14 4 0000 «Хуҗалык итүнең кече рәвешләренә ярдәм» ярдәмче программасы» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә :

«- 5438 Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаны үстерү өчен грант ярдәменә субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаны үстерү өчен грант ярдәменә федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

л) түбәндәге эчтәлекле яңа пунктлар өстәргә:

«1.1.21[1]. «2013 – 2023 елларга
Татарстан Республикасында газ мотор ягулыгы
базарын үстерү» дәүләт программасы»

«2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ мотор ягулыгы базарын үстерү» дәүләт программасының максатчан статьяларына түбәнләгеләр керә:

23 0 0000 «2013 – 2023 елларга
Татарстан Республикасында газ мотор ягулыгы
базарын үстерү» дәүләт программасы»

Әлеге максатчан статья буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 31 декабрендәге карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеге нигезендә әзерләнгән «2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ мотор ягулыгы базарын үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары «2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ мотор ягулыгы базарын үстерү» дәүләт программасы түбәндәге чыгым юнәлешләре буенча башкарыла торган, шул исәптән:

- 5173 Торак-коммуналь хуҗалык өчен газ мотор ягулыгында эшли торган автобуслар һәм техника сатып алу

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча торак-коммуналь хуҗалык өчен газ мотор ягулыгында эшли торган автобуслар һәм техника сатып алуга федераль бюджет

акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 6173 Торак-коммуналь хуҗалык өчен газ мотор ягулыгында эшли торган автобуслар һәм техниканы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән сатып алу

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Торак-коммуналь хуҗалык өчен газ мотор ягулыгында эшли торган автобуслар һәм техниканы сатып алуга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 7171 Торак-коммуналь хуҗалык өчен газ мотор ягулыгында эшли торган автобуслар һәм техника сатып алу өчен алынган кредитлар һәм заемнар буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча торак-коммуналь хуҗалык өчен газ мотор ягулыгында эшли торган автобуслар һәм техника сатып алу өчен алынган кредитлар һәм заемнар буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«1.1.25$^{3}$. «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасы

«2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасы» максатчан статьясына түбәндәгеләр керә:

30 0 0000 «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасы

Әлеге максатчан статья буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 31 декабрендәге 1199 номерлы карары белән расланган чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча башкарыла торган дәүләт программалары исемлеге нигезендә әзерләнгән «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

м) 1.1.26. «Татарстан Республикасы бюджеты һәм Россия Федерациясе дәүләт бюджеттан тыш фондлары чыгымнарның программада каралмаган юнәлешләре» пунктчасында «99 0 0000 Чыгымнарның программада каралмаган юнәлешләре» максатчан статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа чыгым юнәлешләре өстәргә:

«- 6603 2014 – 2020 елларда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программага кертелмәгән күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча 2014 – 2020 елларда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программага кертелмәгән күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

2. 2 нче кушымтада:

а)

«0115161 Дарулар белән тәэмин итү өлкәсендә аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыру»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

«0115482 Гражданнарны дару белән тәэмин итүне яхшырту максатларында чараларны гамәлгә ашыру»;

б)

«0125402 Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең нигез программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәткәндә барлыкка килә торган чыгымнарны финанслашу»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

«0125422 Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары буйсынуындагы медицина оешмалары тарафыннан 2014 – 2015 елларда Украина гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга медицина ярдәме күрсәтүгә һәм эпидемия күрсәткечләре буенча профилактик прививкалар календарена кертелгән профилактик прививкалар ясауга бәйле чыгымнарны компенсацияләү»;

в)

«0224369 Әдәбият һәм сәнгать, мәгариф, басма массакүләм мәгълүмат чаралары, фән һәм техника өлкәсендә премияләр һәм дәүләт алдындагы аерым казанышлар өчен башка бүләкләүләр

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

«0225026 2011 – 2015 елларга мәгарифне үстерүнең федераль максатчан программасы чараларын финанс белән тәэмин итү

0225088 Иң яхшы укытучыларны бүләкләү»;

г)

«0244364 Талантлы яшьләргә дәүләт ярдәме»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

«0245026 2011 – 2015 елларга мәгарифне үстерүнең федераль максатчан программасы чара-

ларын финанс белән тәэмин итү

0245066 Россия Федерациясе халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарәче кадрлар әзерләү»;

д)

«02К0000 «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт» ярдәмче программасы

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

«02К5027 Татарстан Республикасында уңайлы мохитне субсидияләр исәбеннән булдыру чаралары

е)

«0325194 Аерым категориядәге гражданнарга шифаханә-курортта дәвалану, шулай ук дәвалану урынына шәһәрара транспортта барып кайту өлешендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү »

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

«0325209 Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуга, эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтүгә һәм компьютер белеме бирүгә бәйле социаль программаларын субсидияләр исәбеннән финанслашу»;

ж)

«0330508 Халыкны социаль тәэмин итү учреждениеләре»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

«0335209 Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуга, эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтүгә һәм компьютер белеме бирүгә бәйле социаль программаларын субсидияләр исәбеннән финанслашу»;

з)

«0365027 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасының 2014 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасы чараларын субсидияләр исәбеннән гамәлгә ашыру

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«0365027 Татарстан Республикасында уңайлы мохитне субсидияләр исәбеннән булдыру чаралары »;

и)

«0412178 2014 – 2015 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «0415020 | Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән субсидияләр исәбеннән тәэмин итү»; |

к)

| | |
|---|---|
| «04К0000 | «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт» ярдәмче программасы» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «04К5021 | «2011 – 2015 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Россия Федерациясе субъектларының торак төзелешен үстерү программаларын камилләштерү» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыру; |

л)

| | |
|---|---|
| «0814412 | Татарстан Республикасы дәүләт музей-тыюлыклары эшчәнлеген тәэмин итү» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «0815014 | «Россия мәдәнияте (2012 – 2018 еллар)» федераль максатчан программасы чараларын гамәлгә ашыру»; |

м)

| | |
|---|---|
| «0834410 | Мәдәният һәм кинематография өлкәсендәге гамәлләр» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «0835014 | «Россия мәдәнияте (2012 – 2018 еллар)» федераль максатчан программасы чараларын гамәлгә ашыру»; |

н)

| | |
|---|---|
| «0835144 | Муниципаль берәмлекләр китапханәләренең китап фондларын туплау» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «0835146 | Россия Федерациясенең гомумфайдалану китапханәләрен «Интернет» челтәренә тоташтыру һәм, мәгълүмат технологияләрен киңәйтү һәм цифрлаштыру бурычын исәпкә алып, китапханәләр эше системасын үстерү »; |

о)

| | |
|---|---|
| «08В0000 | «2014 – 2020 елларга регионара һәм милләтара мәдәни хезмәттәшлекне үстерү» ярдәмче программасы» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

«08В4405 Грантлар»;

п)

«08Ж4410 Мәдәният һәм кинематография өлкәсендәге гамәлләр»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

«08Ж5014 «Россия мәдәнияте (2012 – 2018 еллар)» федераль максатчан программасы чараларын гамәлгә ашыру»;

р)

«08К0000 «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт» ярдәмче программасы

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

«08К5112 Муниципаль милек объектларына капитал салуларны финанслашу»;

с)

«0940000 «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы су хуҗалыгы комплексын үстерү» ярдәмче программасы»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

«0945016 Татарстан Республикасы су хуҗалыгы комплексын субсидияләр исәбеннән үстерү гамәлләре»;

т)

«1010000 «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» ярдәмче программасы»

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1010000 «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү» ярдәмче программасы»;

у)

«10К0000 «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре, капиталь ремонт» ярдәмче программасы»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

«10К5017 «2008 – 2015 елларга Россия Федерациясендә футболны үстерү» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыру»;

ф)

«1131010 Мәдәният өлкәсендә эшчәнлеккә ярдәм»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

«1135085 Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм чаралары»;

х)

«1142154 Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген һәм эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген арттыру чаралары»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

«1150000 Инновацион территориаль кластерларны үстерү буенча комплекслы инвестицион проектларны субсидияләр исәбеннән гамәлгә ашыру чаралары

1155389 Бюджет учреждениеләренә, автоном учреждениеләргә һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларга субсидияләр бирү

1156389 Инновацион территориаль кластерларны үстерү буенча комплекслы инвестицион проектларны гамәлгә ашыру чаралары»;

ц)

«1340537 Җәмәгать транспорты хезмәт күрсәтүләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

«1345480 Троллейбуслар һәм трамвай вагоннары сатып алу

1346480 Троллейбусларны һәм трамвай вагоннарын Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән сатып алу»;

ч)

«1360355 Татарстан Республикасы автомобиль юллары челтәрен камилләштерү, үстерү һәм саклап калу»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

«1360356 Чаллы шәһәренең сәнәгать зонасында гомуми файдаланудагы юллар инфраструктурасын Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән булдыру

1360357 Чаллы шәһәренең сәнәгать зонасында гомуми файдаланудагы юллар инфраструктурасын «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциягә карамаган оешмасы акчалары исәбеннән булдыру»;

ш)

«1415041 Үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә бәйләнешсез ярдәм күрсәтүгә субсидияләр»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1415450 | Үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен эшкәртүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр»; |

щ)

| | |
|---|---|
| «1416034 | Күпьеллык үсентеләрне утырту һәм карап тоту чыгымнары өлешен каплауга субсидияләр» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1416035 | «2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү» икътисадый әһәмиятле ведомство максатчан региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә субсидияләр»; |

ы)

| | |
|---|---|
| «1416312 | Үсемлекчелеккә ярдәмгә субсидияләр» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1416450 | Үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен эшкәртүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр»; |

э)

| | |
|---|---|
| «1425049 | Терлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгын иминләштерү шартнамәсе буенча иминият премиясен түләүгә авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1425442 | Сөт юнәлешендәге терлекчелек комплекслары объектларын (сөтчелек фермаларын) төзүгә һәм модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр |
| 1425443 | Сөт терлекчелеген үстерүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр |
| 1425444 | Сөт терлекчелеге объектларын төзүгә һәм реконструкцияләүгә инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр |
| 1425450 | Үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен эшкәртүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр»; |

ю)

| | |
|---|---|
| «1426442 | Сөт юнәлешендәге терлекчелек комплекслары объектларын (сөтчелек фермаларын) төзүгә һәм модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1426443 | Сөт терлекчелеген үстерүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент |

ставкасы өлешен каплауга субсидияләр

1426444 Сөт терлекчелеге объектларын төзүгә һәм реконструкцияләүгә инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр

1426450 Үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен эшкәртүгә кыска сроклы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр»;

я)

«1436050 Ит өчен үстерелә торган нәселле мөгезле эре терлек тармагына ярдәм итүгә субсидияләр»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

«1436051 «2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында ит терлекчелеген үстерү» икътисадый әһәмиятле ведомство максатчан региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә субсидияләр»;

я$^{1}$)

«1445056 Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән үзләре файдалана торган җир кишәрлекләрен милек итеп рәсмиләштергәндә крестьян (фермер) хуҗалыкларының, индивидуаль эшкуарларны да кертеп, чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

«1445438 Авыл хуҗалыгы куллanучылар кооперативларына матди-техник базаны үстерү өчен грант ярдәменә субсидияләр»;

я$^{2}$)

«2201099 Программа чараларын гамәлгә ашыру»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

«2300000 «2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ мотор ягулыгы базарын үстерү» дәүләт программасы

2305173 Торак-коммуналь хуҗалык өчен газ мотор ягулыгында эшли торган автобуслар һәм техника сатып алу

2306173 Торак-коммуналь хуҗалык өчен газ мотор ягулыгында эшли торган автобуслар һәм техниканы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән сатып алу

2307171 Торак-коммуналь хуҗалык өчен газ мотор ягулыгында эшли торган автобуслар һәм техника сатып алу өчен алынган кредитлар һәм заемнар буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр»;

я$^{3}$)

«2906474 Инвалидларны социаль тәэмин итү чаралары»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «3000000 | «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасы |
| 3001099 | Программа чараларын гамәлгә ашыру»; |

я[4])

| | |
|---|---|
| «9906045 | Авыл хуҗалыгы өлкәсендә башка гамәлләр» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «9906603 | 2014 – 2020 елларда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программага кертелмәгән күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау». |